КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 июль г.Казань № 709

2022 елда торглар үткәрмичә сатыла торган Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләре яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре өчен бәя билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда Россия Федерациясендә җир мөнәсәбәтләрен җайга салу үзенчәлекләре турында» 2022 елның 9 апрелендәге 629 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының $39^4$ статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда Россия Федерациясендә җир мөнәсәбәтләрен җайга салу үзенчәлекләре турында» 2022 елның 9 апрелендәге 629 номерлы карарының 1 пунктындагы «а» пунктчасында каралган очракларда Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә карата торглар үткәрмичә җир кишәрлеген сату-сатып алу шартнамәсен төзегәндә җир кишәрлегенең бәясе гражданның мондый җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгате кергән вакытта гамәлдә булган җир кишәрлегенең кадастр кыйммәте күләмендә билгеләнә дип билгеләргә.
2. Бу карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры
А.В.Песошин